БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«05» 02 2024 г.

**КАРАР**

№ 70

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында бушлай туклану бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 27 октябрендәге 271 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Укучыларның баланслы кайнар туклану нормаларын үтәүне, аларның сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын яхшырту максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023елның 4 сентябрендәге 1066 номерлы карары, « 2024-2026 елларга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 7 сентябрендәге 1099 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында бушлай туклану бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 27 октябрендәге 271 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.1.«2024 елның 1 гыйнварыннан Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һәр уку көненә 9 сум 20 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар өчен түләүдән торган суммага кайнар ризык белән туклandыруны оештырырга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка

җиткерергә.

3. Әлеге карар 2024 елның 1нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына һәм «Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов